СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

*22 июль, 1998 ел.*
**ЧӘРШӘМБЕ**

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 82 (8239)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# ИГЕНЧЕНЕҢ СЫНАУ СӘГАТЕ СУКТЫ

## "Уңыш -98" матбугат үзәге хәбәр итә

***Районыбыз игенчеләре елның иң зур имтиханына - уракка керештеләр. Быелгы коточкыч корылык шартларында бу урак бигрәк тә мәшәкатьле һәм икеләтә - өчләтә җаваплы - бар булган ашлыкны гына түгел, саламын да учмасына кадәр җыеп алып урнаштыру мөһим. Бу җаваплы чорда авыл эшчәннәренә елдагыча МТСның "Кейс" һәм "ДОН" комбайннары да ярдәмгә чыкты һәм бүген аларның беренчеләре аеруча мобиль файдаланыла.***

***Кичәге көнгә районда уракка унбишләп хуҗалыкта керештеләр. Кырга иң беренче булып чыккан мичуринлылар 270 гектарда уҗым культураларын урырга, шуның яртысыннан күбен суктырырга да өлгерделәр инде. "Татарстан" игенчеләре дә уракта баштан ук кызу темп алды - бер көндә генә 160 гектарда эш башкарып, алар барлыгы 220 гектарда иген урдылар. Хафизов исемендәге, Синдряков исемендәге хуҗалыкларда да кичәге көнгә игене урылган мәйданнар 100 -120 гектар иде. Шунысы игътибарга лаек, башка елларда соңгарак кала торган ...р ягы кырларында да комбайннар эшли инде, ...гебаза ярдәмче хуҗалыгында, "Үрнәк"тә, "Игенче"дә дә игене урылган мәйданнар арта бара. Теземнәрдән җыеп һәм турыдан - туры суктыруда төп игътибар тизрәк уҗым культураларыннан чәчүлек орлык материалы алып калуга бирелә.***

***Ә уҗым чәчү өчен әзер мәйданнар 6 мең гектардан артып китте. "Агрохимсервис" ярдәмче хуҗалыгы кооперативлары быел бу яктан аеруча өлгерлек күрсәтәләр - аларда планлаштырылганның өчтән икесендә җир әзер инде. Ә менә күршеләре РСУ ярдәмче хуҗалыгында бу эш темп алып кына килә әле. Һәм мондый мисалларны башка ызандаш хуҗалыклардан да китерергә мөмкин. Сабан басуларының кайберләрен бүген сөреп куярга мөмкин булуын, сенажга алына торган азык катнашмалары кырлары да бушый баруын искә алсак, уҗым чәчү өчен җир әзерләүнең темпы канәгатьләнерлек түгел әле.***

***Сенажга килгәндә, кичәге көнгә аның запасы 14 мең тонна чамасы иде, коры печән 10 мең тоннадан артып китте һәм соңгысы - ихтыяҗның өчтән бере кадәр. Сусыл азыкның иң күбе "Кондырча"да - 2300 тоннадан артыграк, ягъни кирәк кадәрнең өчтән икесеннән күбрәк, Муса Җәлил исемендәге, "Дуслык", "Үрнәк" хуҗалыкларында да сенаж ишле генә. Ә менә "Родина", "Комбайн", "Төрнәс" һәм "Игенче"дә бу яктан мактанырлык нәрсә юк әле.***

*Куанычлы яңалыклар*

## БЕЗНЕҢ ВӘКИЛ - БЕРЕНЧЕ УНЛЫКТА

***Узган атнада Мамадыш районының "Мамадыш" нәсел заводы базасында көтүне яңарту технологларының республика конкурсы уздырылды.***

Барлык районнардан җыелган технологлар ярышында безнең район данын "Чирмешән" хуҗалыгыннан Мөнир Хәлиуллин яклады. Махсус урта белемле, бу өлкәдә шактый зур тәҗрибәле Мөнир, дүрт этаптан торган конкурсның барлык бүлекләрендә дә әйбәт чыгыш ясап, 100 мөмкинлектән 92 очко җыйды һәм җиденче урынны алды. Үз хуҗалыгында көтүне яңарту, малларны ясалма орлыкландыру эшен тиешле югарылыкта алып баручы белгечнең республикакүләм ярышта да сынатмавы - барыбызга да куаныч.

*Авылга - газ*

## КӘКРЕ АТАУДА БАР, ГӘЙТӘНДӘ ДӘ БУЛЫР

***Узган атнада тагын бер авыл - "Чирмешән"нең Кәкре Атау авылындагы беренче ун йортта челтәр газы кабынды.***

"Востокмонтажгаз"ның 2 нче төзү идарәсе авыл урамнарына газүткәргечләр сузу, йортларны тоташтыру кебек гаять мәшәкатьле эшләрне ай ярым дигәндә яхшы сыйфат белән башкарып чыкты. Һәм менә нәтиҗәсе күз алдында - беренче дистә йортта газ яна, вак - төяк шартлар үтәлеп беткән тәкъдирдә тагын өч дистәдән артык йортны шунда ук челтәр газына тоташтырырга мөмкин.

Хуҗалыкның икенче авылы - Гәйтән халкының да шушы уңайлыкка тиенәсе көннәре ерак түгел.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Нефть һәм газ промышленносте өлкәсендәге хезмәтләре һәм күп еллар буена намуслы эшләгән өчен "Татнефть" акционерлык җәмгыятенең "Нурлатнефть" идарәсе начальнигы **Марат Мөхлис улы ХУҖИНга "Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ промышленносте хезмәткәре"** дигән мактаулы исем бирелде.

## ШТАБТА - МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘЛӘР

***Район хакимияте башлыгы каршындагы оператив штабның дүшәмбе көнне булган чираттагы утырышында көннең аеруча мөһим мәсьәләләре турында сүз барды.***

Штаб җитәкчесе - хакимият башлыгы Ф.С. Сибагатуллин бүген кичектер...сез булган эшләрдән тер... азыгы хәзерләүне тизрәк тоту, уҗым культуралары чәчү өчен җир әзерләүне ашыктыру һәм аны югары сыйфат белән алып бару, бер үк вакытта көзге һәм иртә сабан культураларын урып - җыюга массовый керешү зарурлыгын ассызыклап үтте. Район башлыгы җәйге - көзге кыр эшләрендә хуҗалыкларга шефлык итүче предприятие һәм оешмаларның да техника белән һәм башкача булышырга, бу мөһим чорда җирле үзидарә органнары да читтә калмаска, бигрәк тә кыр культурасын яхшыртуда, юл читләрен, басу буйларын, авылларны чүп үләннәрдән арындыруга көчне туплырга, чәчүлекләрне терлекләрдән таптатмау мәсьәләсен ныклы игътибар үзәгенә алырга тиешлегенә басым ясап үтте.


Штаб утырышында районның социаль -икътисадый үсешенә бәйле башка күп кенә мәсьәләләр дә кузгатылды, аерым алганда, газлаштыруның темплары, юл төзелешенең сыйфаты игътибар үзәгендә булырга тиешлеге ассызыкланды. Хакимият башлыгы финанс - бюджет дисциплинасы, шулай ук башка күп кенә мөһим мәсьәләләрне дә кузгатты.

# УРАКНЫ МИЧУРИНЛЫЛАР БАШЛАДЫ

***Игенче аңа ел әйләнәсе әзерлек алып бара. Җирен эшкәртә, ашлый, чүбенә каршы көрәшә һәм менә - чишелеш: үскәнне, өлгергәнне җыеп алырга вакыт җитә. Мичурин исемендәге кооперативлар берлегендә ул күтәренке рух һәм якты өметләр белән башланды. Урып - җыю темасына беренче репортажыбыз да шул хуҗалыктан.***

Иң беренче уҗым бодае кырларына МТСтан ике "Кейс" килеп төште. Комбайнчылары да инде таныш кешеләр: берсендә Фәнис Гаязов, икенчесендә Нәбиулла Бакиров. Көн әйбәт, урак өчен махсус бирелгән диярсең. Озак та үтми, Владимир Тимофеевның КамАЗ әрҗәсенә шыбырдап беренче ашлык коела башлады. Корылык белән көрәшеп үскән игеннәрнең күпме уңыш бирә алуын дулкынланып көткән игенчеләр исәпләргә керештеләр: гектарыннан 18 - 20 центнер чыга бугай - елына карата зарланырлык түгел, диештеләр. - Ә бит бу 150 гектар чиста пар җирләреннән 50 - 60 центнер күтәрелгән иде,- ди хуҗалык җитәкчесе И.Н.Мөхәммәтов.


Шулай күтәргә нигез дә булган: җир өч тапкыр ашланган, сары игеннәр арасында яшел чүп үләннәре дә санаулы гына күренә. Өстәвенә, орлыгы да бер дигән, беренче репродукцияле Миронов-808 бодае чәчелгән. Ләкин ел - елга туры килми шул. Шулай да күңелне төшерергә ярамый. Булганын үзвакытында җыеп алырга кирәк. Мичуринлы механизаторлар нәкъ шулай уйлыйлар да, анары кырларга "Кейс" лар килеп төшүе дә гомер буе урып - җыюны үз көчләре белән башкарып чыга торган мичуринлыларның мин - минлегенә тими калмый булса кирәк, бодай кырында аларга иркенләргә ирек бирмиләр: туган кырларына бер - бер артлы үзләре юнәләләр. СК - 5ләрдә Станислав Николаев, үзенең улы белән Геннадий Васильев, КПС - 5кә ЖРБ тагып Анатолий Ефимов, Исай Ермуллин, Андрей Вартан килеп төшәләр. Хуҗалыктагы 350 гектар бодайның 150се өченче көннең яртысына төгәлләнеп тә килә иде инде. Ашлыкны КамАЗ белән кырдан ындыр табагына Владимир Тимофеев берүзе ташып тора. Анда аны ышанычлы кешеләр кабул итеп калибрлап киптереп, орлыкка салалар. Орлыклык материал нигездә Сирос Варламов, Гулярди Кульметьевның тырыш кулларында.



*Нәбиулла Бакиров һәм ярдәмчесе Рушат Хәлиуллин.*



*Станислав Николаев һәм ярдәмчесе Денис Саврандейкин.*



*"Кейс"лар басу иңли.*

Хуҗалык өченче ел инде орлыкны үзенә дә, башка хуҗалыкларга да әзерли. Ә быел биредә бу мәсьәләдә тагын да киңрәк эш алып барыла.

- Уңышның нигезе җирен эшкәртүдә генә түгел бит, орлыгы сыйфатлы булу да мөһим. Ел саен аны яңарту өстендә дә эшлибез. Быел менә арыш, уҗым бодаеның безнең шартларда чыдамлыкларын тагын бер исбатлаган яңа сортларын да кушып чәчүлек җирләрен тагын да арттырырга исәплибез,- ди Ильяс Нургалиевич. - Арышлар бодайдан әйбәтрәк булды, аны күбрәк чәчүчеләр оттылар быел.

"Кейс"лар да бодай кырын ике әйләнгәч, арыш кырына киттеләр. Куәтле машиналарга бу җирләрне иңләве дә берни түгел.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

## Хезмәт коллективлары конференцияләрендә

# ЭЗЛӘНҮЛӘР НӘТИҖӘСЕЗ КАЛМЫЙ

***Сайланган курс белән даими алга бару үз шартларын куя, оештыру һәм башкару дисциплинасын ныгытуны сорый. Бу яктан "Нурлатнефть" НГДУсы коллективы алдында торган курс - нефтькә бәяләр төшүдән һәм финанс хәле авырлашудан килеп чыккан кризис хәленнән чыгу. Нефть чыгаручыларның яртыеллык эш йомгакларына багышланган конференциясендә дә сүз шул курсны башкарып чыгу өченниләр эшләнүе турында барды.***

Нәтиҗәләргә килсәк, ике меңле коллектив алты айда 756625 тонна нефть чыгарды һәм шуның 9904 тоннасы - нормадан тыш. НГДУ "биләмәләрендә" эшләүче предприятиеләрнең уртак тырышлыгы белән чыгарылган нефть 56907 тонна ( НГДУ чыгарган барлык нефтьнең 7,5 проценты кадәр) булды. Уртак эшчәнлекне дә кертеп исәпләгәндә, идарә буенча нефть чыгаруны узган елның шул чорындагыдан 27846 тоннага, яки 2,8 процентка арттыруга ирешелде. Шуның исәбенә өстәмә товар продукциясе 21 миллион сумлык булыр дип көтелә. Ә продукция реализацияләүнең рентабельлелеге 32,4 процент, ягъни узган елның алты аендагының 65 проценты кадәр булыр дип исәпләнелә.

Табыш күләме кимесә дә, шуннан планлаштырылган чыгымнар, банк процентларын һәм кредитларны кайтаруны да кертеп, үтәлер дип көтелә. Ирекле табыш калыр дип көтелми, һәм ул булса да, кредитларны каплауга яки предприятиенең үз әйләнеш средстволарын тулыландыруга сарыф ителәчәк.

"Безнең идарәнең "Татнефть" акционерлык җәмгыятендәге төрдәш предприятиеләр арасында чагыштырмача тотрыклы икътисадый хәле минималь эксплуатация чыгымнары тотып нефть алу нормаларын арттыруга ирешкән бөтен коллективның тырышлыгы нәтиҗәсе булып тора", дип билгеләп үтте үзенең докладында идарә начальнигы М.М.Хуҗин.

Идарәдә эксплуатация чыгымнары "Татнефть" буенча иң азы булса да, кызганычка каршы, бездә дә хуҗасызлык, хезмәтнең оештырылуы камил үк булмау, җиһазларны рациональ файдаланмау, җитештерүгә бәйле булмаган чыгымнарга һәм югалтуларга, тик торуларга юл кую очраклары бар әле.

Резервларга килгәндә, алар зур күләмдә дә, вак-төяк саналган нәрсәләрдә дә күренә. Бер генә мисал. Соңгы вакытта тик торучы скважиналар фонды шактый кыскартылды: ел башында андыйлар 103 булса, бүген 70 кенә. Нефть чыгару цехларында тик торучы скважиналар фондын җентекләп тикшереп тиешле карарга килергә мөмкин. Бу юнәлештә икенче ЦДНГда алга китеш бар: бирегә 6 айда озак вакытлар тик торган 11 скважина "кузгатылды". 1нче ЦДНГда эшләми торган скважиналар фондын 40 процентка кыскартырга була.

НГДУда авыр чыгарыла торган запасларны гидродинамик һәм химик - физик ысуллар белән алу системасын камилләштерү эше бара. Ел башыннан шул һәм башка алымнар хисабына гына да 35 мең тонна нефть чыгарылды.

Катламнардагы басымны саклау системасын реконструкцияләү буенча да зур эш алып барыла. Металл - пластмасс торбаларны кулланылышка кертү нефтьүткәргечләрнең тишелү очракларын икеләтә киметергә мөмкинлек бирде. Катламнардагы басымны саклау өчен промышленность суы куллану ярты елда эчә торган суны 30 мең кубик метрга кимрәк сарыф итәргә мөмкинлек бирде.

Конференциядә доклад буенча фикер алышуда катнашучылар да гаять мөһим мәсьәләләргә тукталдылар. Профсоюз комитеты рәисе О.Н.Лизунов күмәк килешүне үтәүнең барышы турында җентекләп сөйләде. Ул идарәдәге 269 хезмәткәрнең санаторийларда һәм ял йортларында сәламәтлекләрен ныгытуларын билгеләп үтте. Беренче ЦДНГ начальнигы урынбасары Р.А. Сингатуллин чыгымнарны киметү буенча нинди чаралар күрелүе турында әйтте. Икътисад бүлеге начальнигы Ф.Х. Зарипова акланмаган эксплуатация чыгымнарының күп булуы һәм алардан качарга мөмкин икәнлеге турында зур борчылу белән сөйләде.

***

Хезмәт коллективы конференциясендә хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы турында сүз булу да табигый иде. Өстәвенә, июнь ахырында гына НГДУда хезмәт куркынычсызлыгын комплекслы тикшерү узды. Абруйлы комиссия идарәдә бу юнәлештә эшнең гомумән алганда уңай баруын, моннан 3 ел элек булган тикшерүдән соң шактый алга китеш күренүен билгеләп үтте. НГДУ начальнигы М.М.Хуҗин һәм баш инженерның куркынычсызлык техникасы буенча урынбасары В.М.Коннов, бу хакта әйтеп, яңача хуҗалык итү шартларында хезмәтне саклау эшен оештыруны тагын да камилләштерү буенча күреләсе чараларга тукталдылар.

***

Конференция кабул иткән карар идарәнең барлык җитештерү эшчәнлеген яхшыртуга юнәлдерелгән иде.

"Эшли дә, нефть чыгара да беләбез, бөтенесе дә үзебездән тора",- диде үзенең йомгаклау сүзендә идарә начальнигы. Ә даими эзләнү нәтиҗәсез калмый.

**В.БУРАЙКИН.**

## Яңалыклар • Яңалыклар

# ТЕРКӘЛҮЕ ҖИҢЕЛ ХӘЗЕР...

***Күптән түгел,төгәлрәге май аенда, Нурлатта ТР Юстиция министрлыгының теркәү палатасы филиалы ачылды. Филиал район хакимияте бинасының аскы катында урнашкан, анда директор итеп белеме буенча юрист, элек район эчке эшләр бүлегенең тикшерү бүлеген җитәкләп, отставкага чыккан Г.М.ТӘМАЕВ билгеләнде.***

***Филиалның эшчәнлеге, төп вазифасы нидән гыйбарәт соң? Гакил Мостафович белән без шул хакта сөйләшәбез.***

- Теркәү органнары оештыру турында Закон 1994нче елдан ук гамәлдә булуга карамастан, әлегә кадәр Россиядә бу эш үзагымына куелган. "Боз"ны Татарстан Республикасы кузгатып җибәрде: бүгенгә ул - Россия регионында теркәү палатасы булган бердәнбер республика. Хәзерге вакытта филиаллар бөтен районнарда ачыла, бәхеткә район хакимияте башлыгы тырышлыгы белән бездә ул алданрак һәм бернинди каршылыксыз оешты: мөһимлеге үз ролен уйнады булса кирәк - теркәү службасы хуҗалык итүдә, бигрәк тә салым системасында тәртип һәм контрольне тәэмин итүгә булышачак.

Район җирлегендә төзелә, ачыла торган һәрнәрсә - акционерлык, чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятьләр, ширкәтләр, шәхси һәм башка предприятиеләр һәммәсе дә филиалда теркәлә. Элек бу эшне башкару үзләренең төп вазифаларына өстәп өч ведомство - райфо, коммуналь милек, хакимият бүлекләрендә берничә кешегә тапшырылган һәм теркәлү процессы җиңел генә үтмәгән. Шуңадыр бүген теркәлү максаты белән килгән кешеләр 20 - 30 минутта эшләрен төгәлләп чыккач, аптырап калалар: элек алар бу мәсьәләләр белән берничә көннәр яки атна буе йөрергә күнгән булганнар, күрәсең.

Кабинетның бушап торганы юк, аеруча шәхси эшмәкәрләр күп теркәлә - бер айдан артыграк вакытка 50 ләп кеше мөстәкыйль эш ачты. Теркәлү взносы андыйларга 84 сум тәшкил итә. Взносларның 70 проценты район бюджетына күчә.

Фермерлык белән шөгыльләнергә теләүче авыл кешеләре дә килә теркәлергә. Мисал өчен Урта Чаллы, Богдашкино авылларында үз җир пайларына башкаларныкын да кушып җирдә хуҗаларча эшләргә, иген үстерергә атлыгып [illegible]ручылар бар. Кызганычка каршы, бу җәһәттән әле хо[illegible] нигез, конкрет закон эшләнмәгән, аларны зур кир[illegible] көтеп тора: теркәлүен теркәләләр, әмма шуннан соң көймәләре комга терәлә - кулларында бер тиен акчалары юк, банктан ссуданы 85 процент белән тәкъдим итәләр. Ул да озак срокка түгел.

Теркәү турында яңалыкларга килгәндә, теркәлү таныклыгы элекке кебек вакытлыча -1-2 елга түгел, ә сроксыз бирелә.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

# НЕМЕЦ КИЕМНӘРЕ НУРЛАТЛЫЛАРГА ДА ТАМАН ГЫНА

**Яңа кәсеп**

***"Л.Толстой урамында "гуманитар ярдәм" өчен җыелган киемнәр саталар",- дигән хәбәрне ишеткәч, без гаҗәпкә калдык: ничек инде, үзе гуманитар ярдәм дә булсын, үзе сатылсын да. Кем шундый "кыек" эш белән шөгыльләнергә батырчылык иткән ик[illegible] дип хәлне урында кызыксынырга булдык.***

Зәңгәр капканы ачып керсәк, йорт эче файдаланы[illegible]гән, әмма әле киярга яраклы промышленность товарлары белән шыплап тутырылган - кайсы эленгән,кайсы тартмаларга салынган. Балалар уенчыгыннан алып, төрле үлчәмдәге өс һәм аяк киемнәре, сумкаларга кадәр бар. Сыйфатлы тукымалардан пөхтә итеп тегелгәннәр. Бәяләре - кулланыш дәрәҗәсенә, сыйфатына карап билгеләнә: кечерәк кием - салым 8 - 15 сум чамасы, кышкылар кыйммәтрәк, әйтик, яхшы гына күренгән кәшимир пальто 200 сум тора.

Сораша торгач, шунысы мәгълүм булды: халык телендә гуманитар ярдәм дигән атама алса да, товарлар бушка килмәгән: "Без аларны Германиядән кайтардык,- ди мөлаем йөзле сатучы кыз,- анда аларны үлчәү белән саталар". Фирмалары Санкт - Петербург шәһәрендә урнашкан һәм аның әйтүенчә, бу шәһәрдә чит илләрдән кайтарылган кулланылышта булган товарлар белән сәүдә итү гадәти хәлгә әйләнгән, ә менә Нурлат кебек провинциядә әлегә бу гаҗәпләнү хисе тудыра. Шуңа карамастан, күзгә ташланган урында булмаса да ("Базарда безгә зур мәйдан кирәк, урын өчен түләү ярты миллион сумга төшә", - ди сатучы. Шунлыктан туганнарының үз йортларында сатарга рөхсәт бирүләрен бик теләп кабул итәләр) сатып алучылар аз түгел: безнең алда гына бер күп балалы ана 150 сумга ике сумка кием - салым, уенчыклар алып китте.

Бу кәсеп алар өчен отышлымы, юкмы? Монысын сатып бетермичә әйтә алмыйлар: чөнки үлчәү белән сатып алганда сайлау мөмкинлеге юк - шактый таушалганнарын ташларга туры киләчәк.Хәер, бушка бирелсә, аларына да ия чыгар әле.

Тагын шул чит илләрнең "юктан бар" ясап әрәм - шәрәмгә юл куймауларына бер мисал түгелме соң бу? Ә нигә гыйбрәт алмаска? Беренчедән, илдә аз керемле, күп балалы, матди яктан кыенлык кичерүче гаиләләр өчен саллы ярдәм булыр иде. Икенчедән, эшсезләргә яңа эш урыны. Файдаланылган киемнәрен ташларга кыенсынып торучылар азмыни хәзер? Рәхим итеп эшлә генә, товарын җый, сәүдә ит... Бары тик теләк кирәк тә һәм стереотиплардан гына арынасы бар.

**Ф.ГАЛИМОВА.**

# УҢГАН ГАЛИМҖАН

Безнең Хафизов исемендәге хуҗалыкның беренче кооперативында Галимҗан Минһебаев дигән уңган тракторчы бар. Менә 19 елга якын инде ул авыл хуҗалыгында хезмәт итә. Соңгы сигез елда Галимҗан ЮМЗ - 6 тракторында эшли. Кышын ул ферма тирәләрен кардан чистарта, фураж төйи һәм бушата, тирес түгә. Урып - җыю вакытында исә ындыр табагында эшли. Үзенә тапшырылган техникага бик сакчыл караштa ул. Тракторы һәрвакыт төзек, эшкә яраклы хәлдә.

Галимҗанның хезмәтен хуҗалык җитәкчеләре дә тиешенчә бәялиләр. Моннан өч еллар элек ул хуҗалык төзеткән яңа йортка күченде. Тату гаиләдә малай һәм кыз үсә, гаилә башлыгы исә көн - төн белән исәпләшми, намуслы хезмәттә.

**Т.ДЕРБЫШЕВ,**
**хәбәрче.**



# ЗАМАНА АВЫРЛЫГЫНА КАРАМЫЙ

***Тимерлек авылы кибетендә Нина 1984 елдан бирле эшли. Шул ук елны Бөгелмә училищесын тәмамлагач, райпо тарафыннан шунда кибетче дә, мөдир итеп тә билгеләнгән иде - ышанычны аклады: чиста, пөхтә, кибетенә товарларны авыл халкы ихтыяҗын өйрәнеп алып кайтырга тырыша. Һәм, әлбәттә, авыл кибетләре өчен авыр чорга зарланып, пошынып тормый, тырыша, таба. Шуңа да аның товар әйләнеше башкаларныкы белән чагыштырганда әйбәт кенә.***

*Рәсемдә: Тимерлек кибете сатучысы Нина Тимофеева.*

*Н.АЗИЗОВ фотосы.*

**Терлекчелектә яңа технология**

# ӨСТЕНЛЕГЕ КҮП, НӘТИҖӘСЕ ЯХШЫ

Мәгълүм булганча, ике ел инде районда малларны бәйләүсез асрау технологиясенә күчү эше бара. Былтыр бу юнәлештә алга таба тагын да зур адым ясалды - берничә хуҗалыкта савым сыерларын бәйләүсез асрап, махсус аппаратлар белән җиһазланган залларда савуга күчтеләр. Узган кышлату чорына һәм кышлату барышында "Камил - Агро" фирмасының зур булышлыгы һәм актив катнашында сигез хуҗалыкта берьюлы 127 сыер саварга мөмкинлек бирә торган 11 зал җиһазлап эшләтелә башлады.

Малларны гадәти ысул белән асрауга караганда бу ысулның өстенлекләре күз алдында. Ул бигрәк тә терлекчеләрнең хезмәтен җиңеләйтү һәм эшләүчеләр санын киметү, шулай ук малларны ашату - эчертүгә, абзарлардан тирес чыгаруга бәйле чыгымнарны, электр энергиясен тотуны сизелерлек азайту җәһәтеннән отышлы. Бер үк вакытта, сөт турыдан - туры суыткычларга агу аркасында продукциянең сыйфаты яхшыру, аның механик пычрануы химү ягыннан да бу ысул үзенең өстенлеген күрсәтте. Барлык бу факторлар продукциянең үзкыйммәтен сизелерлек киметүгә, терлекчеләрнең хезмәтенә түләү артуга да китерде.

Узган кышлату чорында мондый саву заллары хуҗалыкларның үз көчләре белән "Киекле", "Чулпан" КХАларында, промышленность предприятиеләре белән берлектә шикәр заводы һәм нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларында ясап куелды. Язга чыккач "Киекле"дә инде дүртенче залга тотындылар, Мичурин исемендәге, Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкларда берәр, "Үрнәк"тә ике зал ясый башладылар һәм алар хәзер тәмамлану алдында. Санап кителгән барлык бу саву залларында "Камил - Агро" фирмасы көче белән саву аппаратлары монтажланды.

Хәзерге вакытта Хафизов исемендәге хуҗалыкның Ерепкино һәм Кормыш фермаларында, "Татарстан"да Кычытканлы һәм Әлмәттә, Мичурин исемендәге хуҗалыкның Вишневая Поляна фермасында тагын бер зал төзү бара. Моннан тыш, "Рассвет"та "Тандем" системасы буенча тагын бер зал монтажлау тәмамланды, хуҗалыкның Якты Күл фермасында да шундый бер зал эшләнә.

Билгеле ки, саву залы төзеп кенә эш бетми, аннан файдалану өчен сыер абзарларының үзгәртеп корылуы да кирәк. Моның өчен иң элек абзарлардагы элеккеге җиһазларны, тагаракларны, суэчергечләрне сүтеп алырга, капкаларны биегәйтергә һәм киңәйтергә, тәрәзә уемнарын кечерәйтергә һәм азайтырга туры килә. Шуннан соң инде тагаракларны һәм су савытларын яңабаштан урнаштырып, абзарны күчерелеп йөртелә торган киртәләр ярдәмендә дүрткә бүләсе. Тагаракларны урталыкка урнаштыру максатка ярашлы. Моннан тыш, кардаларда да коймаңың буеннан буена утлыклар урнаштырып чыгасы, чөнки яңача асраганда малларга бар азык нигездә кардада өләшенә, ә концентрат азыклар бары тик сауган вакытта гына бирелә.

Бер үк вакытта яңача эш нәтиҗәле булсын өчен башка технологик һәм оештыру мәсьәләләрен дә игътибардан читтә калдырмаска кирәк. Сүз савым көтүен җентекләп ревизияләп чыгу, аларны номерлау турында бара, соңгысы аеруча мөһим, чөнки бәйләүсез асрауга күчкәч элеккеге группалар таратыла һәм сыерлар "иясезләнә". Ә шушы шартларны үтәми торып, малларның физиологик хәлен тикшереп тору, продуктлылыгын исәпкә алу, каплату һәм бозаулату эшендә ныклы учет булдыру, тиешле ветеринар чараларны уздыру мөмкин түгел. Моннан тыш, саву заллары нормаль эшләсен дисәк, малларны абзарларга кайтарганчыга кадәр һәр хуҗалыкта вакуум җайланмалары һәм саву агрегатлары өчен җаваплы операторлар билгеләп, аларның савучы операторлар белән бергә укуын оештырырга кирәк. Яңача эшли торган хуҗалыклар үрнәге бу алымның нәкъ менә шул эш өчен җаваплы махсус кешеләре булып, алар даими эшләгәндә генә уңышлы булуын раслый.

Күренгәнчә, районның шактый хуҗалыкларында сыерларны бәйләүсез асрауга күчерү һәм саву заллары көйләү эшләре уңышлы гына бара. Әмма, яңача эшләүнең өстенлеге инде практикада раслануга да карамастан, кайбер хуҗалыкларда бу юнәлештә тиешенчә эшләмиләр әле. Инде җәй узып барса да, "Игенче", "Таң", "Дуслык", "Заря"да, "Чирмешән"нең Кәкре Атау бүлекчәсендә, Синдряков исемендәге,"Комбайн" хуҗалыкларында, РСУ һәм сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында бу юнәлештә бармакка бармак та сукмадылар диярлек. "Заветы Ильича"да кыш көне шефлары - "Татмелиоводстрой" ПМКсы көче белән башланган эш тә тукталып калды. Ә бит ул хуҗалыкларның берсендә дә диярлек терлекче кадрлар мәсьәләсе бик җиңеллөрдән түгел һәм яңача эшли башлау бары шул күзлектән генә чыгып караганда да күпкә отышлы. Ә көз кергәч кенә тотынып, эшне ахырына җиткерү бик авыр булачак. Саву заллары инде бер кыш эшләгән хуҗалыкларның да кайберләрендә җиренә җиткерәсе мәсьәләләр бар әле. Сүз саву залларын яктырту һәм җылыту, кайнар су белән тәэмин итү, канализация челтәре булдыру турында бара. Шушы ук проблемалар "Сөлчә", "Комбайн", "Чирмешән"нең УДС системасы буенча эшли торган фермаларына да кагыла.

Кыскасы, терлекчелектә конкуренциягә сәләтле, ягъни арзанлы да, мул да продукция җитештерик дисәк, хезмәт һәм энергия чыгымнарын кискен киметергә мөмкинлек бирә торган яңа технологиягә күчмичә мөмкин түгел. Һәм район җитәкчелегенең бу юнәлештә максатчан эше, "Камил-Агро" фирмасының да бар яклап булышлык итәргә әзер торуы урыннарда да киң хуплау табарга тиеш.

**Н.ЛАРИОНОВ,**
**"Камил -Агро" фирмасының инженер - технологы.**

# АЛТЫ АЙДА - 600 МЕҢ СУМ

## *РАЙОН ХУҖАЛЫКЛАРЫ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫКТА ДӘҮЛӘТКӘ САТЫЛГАН СӨТНЕҢ СЫЙФАТЫ АРКАСЫНДА ШУЛХӘТЛЕ АКЧАДАН КОЛАК КАКТЫ.*

**Саннарның беренче баганасы - сөтнең майлылыгы өчен өстәп язылган, икенчесе - I сорттан түбән сыйфатлы сөт сатудан, өченчесе - сөтне тиешле температурага кадәр суытмый тапшырудан югалган акча, дүртенчесе һәм бишенчесе - һәр центнер сөттән һәм барлык югалган акча (сумнарда)**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Синдряков исем. | 1,67 | 0,15 | 1,63 | 0,14 | 1275 |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 1.11 | 0,34 | 1,61 | 0,86 | 3993 |
| "Комбайн" | 1,20 | 0,26 | 2,71 | 1,79 | 6380 |
| Хафизов исем. | 2,43 | 0,97 | 3,29 | 1,91 | 15810 |
| РСУ ярд. хуҗ. | 4,98 | 1,13 | 5,59 | 2,02 | 6587 |
| М.Җәлил исем. | 2,66 | 0,70 | 4,50 | 2,62 | 5180 |
| "Родина" | 0,46 | 0,22 | 2,87 | 2,64 | 9730 |
| "Рассвет" | 3,45 | 0,47 | 5,71 | 2,87 | 18390 |
| "Татарстан" | 3,55 | 0,91 | 5,55 | 3,05 | 25140 |
| "Чирмешән" | 3,10 | 1,63 | 4,95 | 3,59 | 20390 |
| "Төрнәс" | 2,51 | 0,96 | 5,24 | 3,77 | 23640 |
| "Киекле" | 2,78 | 0,38 | 6,25 | 3,93 | 45940 |
| "Игенче" | 0,68 | 0,32 | 4,68 | 4,33 | 16370 |
| "Дуслык" | 1,75 | 0,29 | 6,24 | 4,82 | 16760 |
| "Үрнәк" | 2,95 | 1,58 | 6,54 | 5,27 | 18950 |
| "Чулпан" | 2,47 | 2,88 | 5,12 | 5,61 | 13900 |
| "Сөлчә" | 0,67 | 2,48 | 3,98 | 5,80 | 22140 |
| Кузнецов исем. | -1,18 | 0,44 | 5,00 | 6,64 | 47220 |
| "Заветы Ильича" | -0,45 | 0,54 | 6,11 | 7,10 | 26620 |
| "Кондырча" | 2,77 | 0,70 | 9,13 | 7,12 | 33460 |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 0,99 | 2,56 | 6,07 | 7,65 | 13235 |
| Мичурин исем. | 2,40 | 1,14 | 8,89 | 7,71 | 67610 |
| "Таң" | 1,31 | 2,13 | 7,30 | 8,14 | 16060 |
| "Заря" | -2,98 | 0,70 | 5,12 | 8,82 | 24970 |
| Сөт - май комб. ярд. хуҗ. | 0,91 | 0,03 | 9,96 | 9,09 | 13788 |
| "Алга" | 2,46 | 2,17 | 4,98 | 9,68 | 45490 |
| "Нур" кооп. | -1,77 | 2,18 | 6,61 | 10,60 | 13466 |
| "Каенлык" кооп. | 2,18 | 3,01 | 8,46 | 13,70 | 7290 |
| **Район буенча** | **1,56** | **0,75** | **5,28** | **4,62** | **596720** |

***

Сөт хәзерләүдә кайсы хуҗалыкның күпме акча югалтуы турында мәгълүматларны мондый чагыштырмада беренче тапкыр бирүебез. Моңа кадәр сөтнең сыйфат күрсәткечләрен тиешле таләпләргә җиткермәү аркасында кемнең күпме акчаны алып бетермәвен абсолют саннарда гына китерә торган идек. Әмма авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең план - икътисад бүлеге белгечләре белән берлектә ул югалтуларны нәкъ менә һәр центнер продукциягә күчереп исәпләп чыгару объективрак булыр дигән фикергә килдек. Бу саннар хуҗалык җитәкчеләрен дә, аларның икътисадчыларын, ахырчиктә ферма мөдирләрен, зооветбелгечләрне, лаборантларны һәм, билгеле инде, терлекчеләрнең үзләрен дә уйландырыр дип ышанабыз.

Ә уйланыр нәрсәләр җитәрлек. Мәгълүматлардан аңлашылганча, алты айда абсолют күпчелек хуҗалыклар сөтнең базис майлылыгыннан куерак булуы өчен 2330 центнер, ягъни 198050 сумлык продукциянең өстәп язылуына ирешсәләр дә, аны II -III сорт белән сатудан 16390 һәм 96460 сумны, ә шуны тиешле температурага кадәр суытмыйча тапшырудан 681900 сумны югалттылар. Нәтиҗәдә, майлылык өчен өстәлгән акчаның яртысын I сорттан түбән сөт сату "йотты", калганы суытылмыйча сатылган сөткә "кереп бетте". Нәтиҗәдә, хуҗалыклар 6 айда 600 мең сум чамасы өстәмә акчаны алып җиткермәделәр. Шунысы аяныч, аның яртысыннан күбрәге, ә кайбер хуҗалыкларда аннан да артыграгы июнь аена туры килә. Ә сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыгында бар югалту июньдә булды диярлек.

Сөтне суытып сату өчен өстәмә түләнә торган акча белән суыту чыгымнары арасындагы чагыштырмага карата фикерләр төрле. Бу җәһәттән хуҗалыкларның икътисадчылары үз фикерләрен газета аша уртаклашсалар яхшы булыр иде дибез.



*"Төрнәс" хуҗалыгында көтүне яңарту техникы булып эшли Флюра. Урта мәктәпне тәмамлагач ,4 ел савымчы булып эшләгән иде. Шул чакта җитәкчелек кызның тырышлыгын күреп, махсус белгечлек буенча курсларга барырга тәкъдим итте. Менә шуннан бирле Флюра - хуҗалыкта терлекчелек үсеше өчен иң җаваплы кешеләрнең берсе. Узган елда һәр 100 сыердан 98 бозау алдылар монда, быел алты айда да күрсәткечләре әйбәт. Шулай итеп, терлекчелекнең хәлен тотрыклы итүдә Флюраның да өлеше зур.*

*Ире Исмәгыйль дә терлекчелектә эшли. Үз хуҗалыгында да мең төрле мәшәкать көтеп кенә тора. Гаиләдә ике бала үсә. Һәм ул тату, тигез, эшчән гаиләнең учагын саклау янә дә Флюраның изге бурычы бит.*

*Рәсемдә: Флюра Гариф кызы Галимова.*

*Н.АЗИЗОВ фотосы.*


## БЕЛДЕРҮЛӘР

### АЛМАШТЫРАБЫЗ ЯКИ САТАБЫЗ

**Шикәр заводында ике бүлмәле фатирны - өстәмә түләп бер бүлмәлегә. Яки сатабыз.**

Адрес: Завод ур., 15 - 9 (арадашчы аркылы).

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Бер бүлмәле фатир биреп торам.** Тел.: 5-25-85.

***

**Нурлат шәһәренең 2 нче мәктәбен 1993 елда тәмамлаган 11 Б классының очрашуы 1998 елның 25 июлендә - шимбә көнне була.**

Белешмәләр өчен тел.: 5-22-06( Ләйсән), 2-11-48 ( Наташа).

***

**Кондырча елгасы ярында Владимир Александрович Афанасьев исеменә бумажник, паспорт, шофер таныклыгы, тех.паспорт һәм башка документлар табучының 1000 сум бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен үтенеп сорыйм.** Адрес: Кошки авылы, 60 лет Октября ур., 42, тел.: (код) 8-846-50 2-12-56, 2-28-34.

# *Тәлгат Галиуллин*

***Якташыбыз, күренекле галим, әдәбият белгече, академик Тәлгат Галиуллинның бүген туган көне. Аны 60 яше тулу белән кайнар котлыйбыз һәм укучыларыбызга галимнең автобиографик язмаларының йомгаклау өлешен тәкъдим итәбез.***



# ГОМЕР ТӘЛГӘШЛӘРЕ

## АПАЛАР, СЕҢЕЛЛӘР...

**(Ахыры.Башы 65 -67, 71-81 нче саннарда).**

Әтинең сеңелләре арасыннан минем рухыма иң якыннарының берсе - Рәһбәр, безнеңчә, Шәкерт апа. Соңгы ачыкламышы кушамат түгел, ә кешенең җисеменә, һөнәренә, табигый сәләтенә яраклап әйтелгән мактаулы, яратулы, иркәләүле нисби билгеләмә. Минем "гувернанткаларым" арасында ул мөнәзе белән иң гадие, халыкчаны һәм ихласы иде дип беләм.

Киңчәрәк битле, сылу, зифа буйлы Рәһбәр апа пөхтә итеп киенә, булганны саклап тота белүе белән яшьтән аерылып торды. Аның һәр хәрәкәте, алдан уйланылып куелган шикелле, табигый килеп чыга. Әйтик, ул кулларын, мәшһүр җырчыларыбыз мәсле, кая куярга белмичә интекми. Аларга һич югында гамәли эш табып тора.

Безнең нигездә филологлардан торган нәселдә улберенче белемле математик, физик. Укытучылар институтын уңышлы тәмамлагач (сугыштан соң Чистай, Алабуга, Бөгелмә шәһәрләрендә тулы булмаган югары белем биргән шундый уку йортлары эшләп, кадрларга кытлыкны каплап килде), аны Аксубай вилаятенең Карасу авылы мәктәбенә җибәрәләр. Язмышы, насыйбы шунда булган икән.

Яшь укытучы, зурлап җыенып эшкә китүгә берничә айлап узуга, безнең өй янына пыр - пыр килеп, матай килеп туктады. Парланган тәрәзәләргә ябырылдык. Озын буйлы, тартык яңаклы егет үзе генә түгел, артында кыска, ак сакаллы бер карт утыра. Күргән - белгән кешеләребез түгел. Мин, беренчеме - икенчеме сыйныф укучысы, әлеге бабайның бер чалбарын өскәрәк кайтарып куйганын күреп, гаҗәпләнмәдем, мотоцикл чылбыры балагын азгын бозау кебек эләктереп алмасынга шулай иткәндер, дип юрадым. Ә ул, ходаның рәхмәте белән, яучы булып чыкты. Әти, әни өйдә, исәнлек, саулык сорашып, дога кылганнан соң, "сакал" сүзен үзенә кирәк сукмакка төшерде.

- Карасуда, Нәбиулла туган, сине беләләр, хурмәт итәләр. Ул бик җакшы кеше, бар да үзе белән сүләш, гозереңнне аяк астына салып таптамас. Тастымал сорап бармыйсың, диделәр.

Сүзнең ни нәрсә хакында баруын төшенгән әти агарынып китте. Һәр елны бер туй - күбрәккә китә.

-Рәһбәрне сорап килгәнегезне аңладым инде. Без аны шундый нужа белән укытып чыгардык. Семьяга ярдәме тияр дигәниек. Миңа аңардан берни кирәкми. Әтиләре - вафат. Сеңелләрен аякка бастырасы бар.

Галинең үз юлы, Вәлинең үз Мәккәсе. Башкода әтинең ихластан моң - зарын йонлы колагы аша үткәреп, зиһененә алып тормыйча, тәртәне үз ягына каера.

- Нәбиулла энем, янында әле сеңелләрең кала. Малаең кул астына керә бара,- дип, минем якка кизү ишарә ясап, алып килгән "товарын", минем булачак җизнине, мактарга керешә. Әтисен гражданнар сугышындамы, басмачлар белән көрәшкәндәме үтергәннәр икән, әнисенең бердәнбер малае, илләм уңган механизатор икән Тәлгать Шәрәфетдинов.

Булачак җизнигә текәлебрәк карап, Шәкерт апаның мәҗмугаи хәлен аңладым. Җиңел хәрәкәтле, зыялы йөзле, бик чибәр иде егет. Дәрте гәүдәсенә сыймый. Матур. Коңгырт күзләренә зәңгәрсу дулкын йөгергән, чәчләре кабарып тора. Нечкә иреннәрендә хәйләкәр елмаю бии. Йөзенә эчке шатлыгы җәелгән. Аңа ни: өлкәннәр бәхәсләшсен, туарылсын, кызның ризалыгы алынган. "Әзидән рөхсәт алып кайтуга, мин синеке",- дигән сүзләре җанын бәлзәмдәй җылытып тора. Ул да нәрсәдер әйтергә тиештер.

-Нәбиулла абый, сеңелләргә ярдәм итәрбез, укытырбыз. Рәһбәр белән без ни...

Яратыштык, вәгъдәләр бирештек, дип әйтәсе килгәндер инде. Җир кешесенең теле купшы сүзләргә өйрәнмәгән шул. Рәһбәр апага сандугачыңнан ким сайрамагандыр әле. Ә биредә чит - ят кешеләр, һәр сүзне хәтерләп, йотып барган бала - чага... Ул туктап, төртелеп калды.

Әби,кызның әнисе, ирләр эшенә катышмаган булып, яхшатланып утырса да, йөрәк пәрәсенең язмышына битараф кала алмады. Кызларны вакытында тапшыруның олы бер гамәл, изге бурыч икәнен ул яхшы үзләштергән. Билгеле бер яшькә җиткәч, базарда алучысын таба алмыйча эленеп торып уңа, төсен, ямен җуя барган кызыл малныкыдай һәр узган көн кызның бәясен төшерә.

- Нәбиулла улым, - ди әби ишетелер - ишетелмәс кенә,- ирләр сүзенә кысыласым килми. Шулай да әйтим инде: үзләре табышкач, ярашкач, әллә фатиханы бирәсеңме? Ятим үскән бала ди, кызыбызны рәнҗетмәс, иншалла.

Рәһбәр апа белән адаш җизни бик яратышып, тату, үрнәк гаилә булып яшәделәр. Хуҗа ташып торган кызу канлы, җиңел холыклы. Чи борчак биетерлек кызган таба инде. Шәкерт апа тыныч, сабыр. Ир белән идарә итүнең юлларын чамалый. Шулай алар тормыш йөген бергә тартып, өч малай, ике кыз үстерделәр, хәлләреннән килгәнчә, барыбызга да ярдәм иттеләр.

Хәзер Рәһбәр апа лаеклы ялда. Буш вакытын оныкларына, дингә, мәрхәмәткә багышлый. Һәркемнең үз язмышы, үз йолдызы.

***

Кешенең галәм тормышы белән чагыштырганда бик кыска гомере берничә чорга бүленә икән. Ун - унике яшькәчаклы әле синең сөекле бала булып, иркәләнеп яшәргә хакың бар. Егермегә кадәр үзеңне ихластан егет кеше, бәйсез инсан дип йөртә аласың. Бераздан үзеңнең өлгереп җитеп, гаилә корып җибәрергә, кемнәр өчендер җаваплы булып яши башларга тиешлегеңне сизәсең. Бу инде дуамал яшьлек яшьнәп узып киткән дигән сүз. Утызның аргы ягына чыккач, кырык, илле, алтмыш... кебек саннар, безнең илдә акча алышынган тизлек белән килеп җитәләр, узып китәләр икән.

Хатирәләр - истәлекләр кешедән тизрәк картая, әмма кәгазьгә төшерсәң, ул вакыт белән санашмый, аның өчен яшьнең әһәмияте юк. Менә шуңар да шәҗәрәмнең, тәрҗемәи хәлемнең бер өлешен, хәтта кыйпылчыгын эченә алган язмаларымны кәгазьгә төшерергә җөрьәт иттем. Истәлекләремнең бу кисәген Роберт Әхмәтҗанов каләменнән төшкән юллар белән төгәллисем килә:

Яланаяк
Барам дөнья буйлап,
Барасы юл, шөкер,
Бетмәгән.

**1997,1998 ел.**

# *КОТЛЫЙБЫЗ!*

Гаиләбезнең җаны,рухы булган **Зөлфия Мифтах кызы Вәлиеваны** туган көне белән котлыйбыз!

Бик кадерле җан син безгә,
Ай - кояшка тиң күрәбез.
Бәхетле бул, озак яшә,
Гаилә нуры Зөлфиябез.

**Изге теләкләр юллаучы ире Надир, улы Илшат, кызы Люция, кияве Илнар, оныгы Ләйлә.**

Колбай Мораса авылында яшәүче кадерле **әниебез, әбиебез Әлфия Фоат кызы Гайнетдинованы** туган көне белән котлыйбыз. Шатлыкларның иң олысын, тынгы белмәс йөрәгеңә сихәтлек, киләчәк көннәрең кайгысыз булуын телибез.

Озын гомер бирсен, ходай дибез,
Кояш сиңа бирсен яктылык.
Балаларың гына түгел, оныкларың
Китерсеннәр сиңа яхшылык.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәше, балалары, кияү - килennәре, оныклары.**

Кадерле хезмәттәшебез **Зөлфия Мифтах кызы Вәлиеваны** туган көне белән котлыйбыз. Бүгенгедәй тормышның ямен тоеп, бәхетле һәм кадерле булып озак еллар яшәвен телибез, хезмәттәшләренең ихтирамы һәм мәхәббәте исә аңа һәрчак тугры юлдаш булыр.

**"Дуслык" газетасы хезмәткәрләре.**

Кычытканлы авылында яшәүче кадерле **әниебез һәм әбиебез Гайшә Ярулла кызы Мөхәрләмованы** 70 яшьлек юбилее белән котлыйбыз.

Бетмәс бәхет һәрчак юлдаш булсын,
Күтәренке булсын күңелең.
Сәламәтлек, куанычлар белән
Үтсен, әнкәй, калган гомерең.

**Иң изге теләкләр белән этиебез, улларың - кызларың, киленнәрең - кияүләрең һәм оныкларың исеменнән улың Гаваз.**

Нурлатта яшәүче кадерле **әтиебез, бабабыз Мансур Нуриҗан улы Әһлиуллинны** 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз.



Ходай сиңа сәламәтлек бирсен,
Син булганга әебез нур чәчә.
Киңәшчебез, терәгебез булып
Яшә әле, яшә йөзгәчә.

**Изге теләкләр белән әнисе, тормыш иптәше, барлык балалары исеменнән Марат.**

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## САТАБЫЗ

**Кече Камышлы авылында йорт.** Адрес: Гыйматдинов ур., 74 - 2.

***

**9 х 9лы бура һәм 40 данә нарат бүрәнәсе. Бәясе- 12 мең сум. Берсен 200 сумнан 50 см.лы 60 данә фундамент блоклары.** Адрес: Шашин ур., 27 - 13, Гарифуллинга.

***

**Мотоблок таккычы белән бишекле "Иж - Планета" мотоциклы.** Тел.: 5-36-50.

***

**Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир.** Тел.: 2-17-57.

***

**Газ белән җылытыла торган йорт.** Иске Чаллы авылында Нина Артамоновага мөрәҗәгать итәргә.

***

**Ике бүлмәле фатир.** Тел.: 2-22-38.

***

**Йөк һәм пассажирлар ташый торган яңа "Газель - 2705".** Белешмәләр өчен тел.: 5-16-33.

***

**Әфган поселогында фундаменты белән участок.** Тел.: 5-26-08, кичке 4тән соң.

**1979 елгы ГАЗ - 53, сатулашырга була.** Тел.: 5-22-60.

**Кулланылышта булган стенка.** Тел.: 5-12-69, 5-33-97.

***

**Азык - төлек комбинаты артында бәрәңгесе утыртылган 6 сутый җир.** Тел.: 2-17-76.

***

**1998 елның апрелендә чыккан, 4 мең км. юл йөргән, чия төсендәге ВАЗ- 21093.** Тел.: 5-21-70, кичке 5тән соң.

***

**1997 елның 30 июлендә чыккан "Газель" (тентлы, 6 урынлы).** Тел.: 2-13-62.

***

**Әйбәт хәлдәге, 76лы бензин белән эшли торган ВАЗ - 2105, арзан.** Адрес: Циолковский ур., 33- 2.

***

**Ашыгыч төстә 8 х 8 бура, Әфган поселогында йорт төзү өчен 10 сутыйлы участок. 10 мең сум.** Тел.: 5-24-62.

## АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Шәһәр үзәгендә барлык коммуникацияләре үткәрелгән йортны - 2 берәр бүлмәле яки өстәмә түләп бер бүлмәле фатирга.** Адрес: Мичурин ур., 2.

***

**Шәһәр үзәгендәге өч бүлмәле хосусыйлаштырылган фатирны - ашыгыч төстә ике һәм бер бүлмәлеләргә.** Адрес: Мәктәп ур., 13 - 17, кичке 5тән соң.

***

**Кормыш микрорайонында өч бүлмәле фатирны- өстәмә түләп бер бүлмәлегә (икенче , өченче катта булса әйбәтрәк), шикәр заводы һәм тимер юлдан тәкъдим итмәскә.** Тел.: 5-16-42, кичке 6дан соң.

***

**Өч бүлмәле фатирны - өстәмә түләп ике бүлмәлегә.** Тел.: 5-21-99, 5-23-95.

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## САТАБЫЗ

**Шәһәр үзәгендә бер бүлмәле фатир.** Адрес: Мәктәп ур., 11- 26.

***

**13 мең км. юл йөргән, 1997 елгы ВАЗ - 21091 двигателе, кыйммәт түгел.** Тел.: 3-83-81.

***

**Әфган поселогында 10 х 12ле яңа кирпеч йорт, эчке эшләре эшләнмәгән верандасы бар, участогы әйләндереп алынган, кыйммәт түгел.** Тел.: 2-18-21.

***

**Куйбышев ур., 43 - 3 адресы буенча 29,4 кв. метрлы хосусыйлаштырылган фатир.**

***

**1, 3, 5 мм. калынлыгында калай, гараж капкасы, 7 х 4 тимер гараж.** Адрес: Димитров ур., 7, тел.: 5-41-64.

**"Нурлатгаз" ЭПУсы кайнар су бирешле һәм катнаш газ мичләре сата, бәясе 2100 сум.** Адрес: Гыйматдинов ур., 158.

**"Тойота - Карина" автомашинасы. Вариантлар мөмкин.** Адрес: Нефтьчеләр ур., 9 - 16.

***

**Автовокзал каршында 1 бүлмәле фатир.** Адрес: Пушкин ур., 45 - 8.

***

**Шифаханә ягында гараж.** Тел.: 5-21-94.

***

**76мм.лы цинкланган торбалар, 50 х 50ле почмаклы тимер.** Тел.: 5-37-91.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2337 данә З. № 2954